**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 5 февраль № 73

г. Казань

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм

Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада:

12 нче пунктта 2 графада «Авыл хуҗалыгы оешмаларында һәм крестьян фермер хуҗалыкларында тулаем авыл хуҗалыгы продукциясе артымы, узган елга карата процентларда» сүзләрен «Авыл хуҗалыгы оешмаларында һәм крестьян фермер хуҗалыкларында тулаем авыл хуҗалыгы продукциясе күләме, узган елга карата процентларда» сүзләренә алмаштырырга;

13 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «13 | «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган, «Заявка хәл ителде» статусы бирелгән хәбәрнамәләр өлеше, процент | Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы | квартал саен (арта барган нәтиҗә белән) | V=A/B×100,<br>монда:<br>A – хисап чорында «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган**, «Заявка хәл ителде» статусы бирелгән хәбәрнамәләр* саны (арта барган нәтиҗә белән), берәмлек;<br>B – хисап чорында «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган** хәбәрнамәләрнең* гомуми саны (арта барган нәтиҗә белән), берәмлек;<br>*хәбәрнамәләр саны – «Эшләүдә», «Планлаштырылды», «Хәл ителде», «Мотиваштырылган баш тарту» баганаларындагы хәбәрнамәләр суммасы;<br>**урнаштырылган хәбәрнамәләр – ел башыннан билгеләнгән чорда эшкәртүдә булган хәбәрнамәләр саны (арта барган нәтиҗә белән)» |

түбәндәге эчтәлекле 15[1] нче пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «15[1] | Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып, торак-коммуналь хезмәтләр өчен электрон түләүләр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | квартал саен (арта барган нәтиҗә белән) | V=A/B×100,<br>монда:<br>A – хисап чорында Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр суммасы (арта барган |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | өлеше, процент | | | нәтиҗә белән), берәмлек;<br>В – хисап чорында торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрнең гомуми суммасы (арта барган нәтиҗә белән), берәмлек». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\73.docx